**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4571**
**14.09.2020**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гражданнар оборонасы хезмәтләре турында

Халыкны һәм шәһәр территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау максатында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен (гражданнар оборонасы хезмәтләрен) оештыру турында» 2010 елның 15 гыйнварындагы 6 номерлы карары, шәһәр Уставының 53 статьясы нигезендә, Яр Чаллы шәһәре территориясендә гражданнар оборонасы чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Авария-коткару эшләрен үткәрү өчен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гражданнар оборонасы хезмәтләре оештырырга.

2. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең гражданнар оборонасы хезмәтләре турында нигезләмәне 1 нче кушымтада каралганча;

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең гражданнар оборонасы хезмәтләре исемлеген һәм составын 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 14 сентябрендәге
4571 номерлы карарына
1 нче кушымта

Гражданнар оборонасы хезмәтләре турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Гражданнар оборонасы хезмәте - гражданнар оборонасы буенча чаралар үткәрү, авария-коткару формированиеләренең гамәлләрен һәрьяклап тәэмин итү һәм хәрби конфликтларда яки конфликтлар нәтиҗәсендә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә һәм террорчылык актларында башка кичектергесез эшләрне башкару өчен билгеләнгән гражданнар оборонасы идарә органнарының, көчләренең һәм чараларының җыелмасы.

2. Гражданнар оборонасы хезмәтләре тыныч вакытта, кирәк булганда, табигый һәм техноген характердагы, шулай ук террорчылык актлары нәтиҗәсендә барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү чараларында катнашу өчен җәлеп ителергә мөмкин.

3. Гражданнар оборонасы хезмәтләре үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү буенча Россия Федерациясе министрлыгының норматив хокукый актлары, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына таянып эш итәләр.

4. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә түбәндәге гражданнар оборонасы хезмәтләре оештырыла:

1) инженерлык;
2) сәүдә һәм туклану;
3) медицина;
4) коммуналь-техник;
5) җәмәгать тәртибен саклау;
6) янгынга каршы;
7) элемтә һәм хәбәр итү;
8) транспорт;
9) ягулык-майлау материаллары белән тәэмин итү;
10) юл;
11) энергетика;
12) санитар-эпидемиологик күзәтчелек;
13) мәдәни кыйммәтләрне саклау.

2 бүлек. Гражданнар оборонасы хезмәтләре тарафыннан башкарыла торган чаралар

5. Гражданнар оборонасы хезмәтләренең гомуми функцияләре булып тора:

1) хезмәтләр эшчәнлеге профиле нигезендә гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү;

2) гражданнар оборонасы хезмәтенең идарә органнарын, көчләрен һәм чараларын гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү буенча бурычларны үтәүгә әзерләү;

3) гражданнар оборонасы хезмәте составына керә торган көчләрне һәм чараларны, шәхси состав белән комплектлануны, техника белән тәэмин ителешне һәм мөлкәт белән тәэмин ителешне исәпкә алу;

4) авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр үткәрү барышында штатта булмаган авария-коткару формированиеләренең гамәлләрен тәэмин итү;

5) гражданнар оборонасының башка хезмәтләре белән, гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр буенча тиешле идарә органнары белән үзара бәйләнешне оештыру һәм дәвам итү;

6) гражданнар оборонасы хезмәтләренең шәхси составын, техникасын, мөлкәтен аварияләр, һәлакәтләр һәм табигый бәла-казалар, заманча химик, атом-төш һәм башка зарарлану чаралары йогынтысыннан һәм тискәре нәтиҗәләреннән саклау.

6. Эшчәнлек профиленнән чыгып, гражданнар оборонасы хезмәтләренең функцияләре булып түбәндәгеләр тора:

1) инженерлык хезмәтләре:

- тыныч вакытта һәм сугыш вакытында гражданнар оборонасының инженерлык-техник чараларын эшләү һәм тормышка ашыру;

- гражданнар оборонасының саклагыч корылмалары һәм аларның техник системалары төзелешен, техник хезмәт күрсәтү һәм билгеләнеше буенча файдалануга даими әзерлек хәлендә тотуны оештыру һәм контрольдә тоту;

- тыныч вакытта һәм гражданнар оборонасын тыныч вакыттан сугыш вакытына күчергәндә, җир астында урнашкан бүлмәләрнең, яшеренү урыннарының һәм халыкны качырып тору өчен корылмаларның эшчәнлеген контрольдә тоту һәм исәпкә алу;

- гражданнар оборонасын тыныч вакыттан сугыш вакытына күчергәндә гражданнар оборонасының тиз төзелә торган саклану корылмаларын (гадиләштерелгән эчке җиһазлар белән) һәм гади типтагы ышыклану урыннарын төзү һәм тыныч вакытта - әзерләү;

- гражданнар оборонасының саклану корылмаларында халыкның ышыклануын тәэмин итү;

2) сәүдә һәм туклану хезмәтләре:

- халыкны азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар белән нормалаштырылган тәэмин итү;

- азык-төлек һәм беренче чиратта кирәкле сәнәгать товарлары запасларын яклау һәм саклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

- азык-төлек запасларын ышыклану урыннарына һәм идарә пунктларына туплауны оештыру;

- урнашу районнарында, авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр үткәрү районнарында штатта булмаган авария-коткару формированиеләренең шәхси составының, шулай ук зыян күргән халыкның туклануын тәэмин итү;

3) медицина хезмәтләре:

- гражданнар оборонасы чараларын медицина белән тәэмин итү;

- зыян күрүчеләрне дәвалау учреждениеләренә эвакуацияләүне оештыру һәм гамәлгә ашыру;

- штатта булмаган авария-коткару формированиеләренең шәхси составына үз вакытында медицина ярдәме күрсәтү;

- йогышлы авырулар барлыкка килүне һәм таралуны кисәтү;

4) коммуналь-техник хезмәтләр:

- су белән тәэмин итү системаларының һәм чыганакларының ышанычлылыгын арттыруга юнәлдерелгән чараларны эшләү һәм үткәрү;

- коммуналь хезмәтләрнең сугыш вакыты шартларында эшләргә әзерлеген тәэмин итү, аларның эш планнарын эшләү;

- су белән тәэмин итүнең зыян килгән системаларын ремонтлау өчен җиһазлар һәм запас частьләр запасларын булдыру;

- суны чистарту һәм транспортлау өчен мобиль чаралар резервын булдыру һәм әзерләүне контрольдә тоту;

- резервуарлар һәм сыешлыклар, җыела-сүтелә торган үткәргеч торбалар, мобиль резерв һәм автоном энергия чыганаклары, башка кирәкле җиһазлар һәм техник чаралар запасларын булдыру;

- халыкка коммуналь-көнкүреш хезмәтләре күрсәтү;

- сакланып калган торак фондын инвентаризацияләү һәм зыян күргән торак фондының торышын бәяләү, аны зыян күргән халыкны урнаштыру өчен файдалану мөмкинлеген билгеләү;

- халыкны санитар эшкәртү, биналарны һәм корылмаларны зарарсызландыру, техниканы һәм территорияләрне махсус эшкәртү өчен дезактивация, дегазация һәм дезинфекция матдәләре һәм эремәләре запасларын алдан ук булдыру;

- халыкны санитар эшкәртү, техниканы, биналарны һәм территорияләрне зарарсызландыру өчен гражданнар оборонасы көчләрен булдыру, шулай ук аларны җиһазландыру һәм гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерләү;

- ихтимал булган күмү урыннарын алдан билгеләү һәм әзерләү;

- мәетләрне тиз арада күмү чараларын тәэмин итү өчен гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын булдыру, әзерләү һәм әзерлектә тоту, законнарда билгеләнгән кагыйдәләрне үтәп, аларны күмүне оештыру;

5) җәмәгать тәртибен саклау хезмәтләре:

- җәмәгать тәртибен саклау көчләрен булдыру, аларны матди-техник чаралар белән тәэмин итү һәм гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерләү;

- җәмәгать тәртибен торгызу һәм саклау;

- торак пунктларда, халыкны эвакуацияләү һәм гражданнар оборонасы көчләренең хәрәкәт итү маршрутларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү;

- хокук саклау органнары тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле объектларны һәм юридик һәм физик затларның мөлкәтен саклау (килешү нигезендә), караучысыз калган мөлкәтне саклау буенча чаралар күрү;

- законнарда билгеләнгән кагыйдәләрне үтәп, мәетләрне тану һәм исәпкә алу чараларын оештыру һәм үткәрү;

6) янгынга каршы хезмәтләр:

- янгынга каршы кирәкле көчләр булдыру, аларны матди-техник чаралар белән җиһазландыру һәм гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерләү;

- гадәттән тыш хәлләрне һәм янгыннарны бетерү буенча авария-коткару һәм башка эшләр үткәрү районнарында янгыннарны сүндерүне оештыру;

- сугыш вакытында, билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы категорияләренә караган объектларда янгыннарны сүндерү;

7) элемтә һәм хәбәр итү хезмәтләре:

- халыкка үзәкләштерелгән хәбәр итү системасын булдыру һәм даими әзерлек хәлендә тоту, аны яңа буын техник чаралары базасында модернизацияләүне гамәлгә ашыру;

- локаль хәбәр итү системаларыннан файдалану;

- кешеләр күпләп җыела торган урыннарда халыкка хәбәр итүнең һәм белдерүнең махсуслаштырылган техник чараларыннан файдалану;

- бердәм электр элемтәсе челтәре чараларыннан, чыбыклы радио һәм телевизион тапшырулар челтәрләре чараларыннан, шулай ук мәгълүмат тапшыруның башка техник чараларыннан комплекслы файдалану;

8) транспорт хезмәтләре:

- халыкны транспортның барлык төрләре белән эвакуацияләүне, эшче сменаларны алып баруны (алып кайтуны), саклау корылмаларын төзү өчен материаллар алып баруны, шәһәр читендәге зонага матди һәм мәдәни кыйммәтләр, уникаль җиһазлар, азык-төлек һәм башка матди чаралар чыгаруны, зарарлану чыганакларында, катастрофик су басу зоналарында, шулай ук гадәттән тыш хәлләр районнарында авария-коткару һәм башка

кичектергесез эшләрне үткәрү өчен гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын алып баруны оештыру;

9) ягулык-майлау материаллары белән тәэмин итү хезмәтләре:

- Яр Чаллы шәһәре территориясендә гражданнар оборонасы чараларын үткәрү өчен җәлеп ителә торган автотранспорт һәм инженерлык техникасын ягулык һәм майлау материаллары белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны планлаштыруны һәм үткәрүне оештыру;

10) юл хезмәтләре:

- гражданнар оборонасы чараларын юл-күпер белән тәэмин итүне оештыру һәм гамәлгә ашыру;

- юлларны һәм күперләрне ремонтлау, торгызу һәм әзер килеш тоту;

- гражданнар оборонасы көчләренең хәрәкәт маршрутларында һәм эвакуация маршрутларында урау юллар булдыру;

11) энергетика хезмәтләре:

- энергетика хезмәтенең эш планын эшләүдә катнашу;

- энергия белән тәэмин итү системаларының һәм чыганакларының ышанычлылыгын арттыруга юнәлдерелгән чаралар эшләү һәм үткәрү;

- билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы категорияләренә караган оешмаларның демаскировка билгеләрен киметү буенча инженерлык-техник чаралар үткәрү;

12) санитар-эпидемиологик күзәтчелек хезмәтләре:

- халык сәламәтлеген, формированиеләрнең шәхси составын саклауга, йогышлы авырулар барлыкка килүне һәм таралуны кисәтүгә юнәлдерелгән санитар-гигиена һәм эпидемиягә каршы чараларны гамәлгә ашыру;

13) мәдәни кыйммәтләрне саклау хезмәтләре:

- шәһәр территориясендә урнашкан мәдәни кыйммәтләрне, тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне яклауга һәм саклауга юнәлдерелгән чараларны планлаштыруны оештыру һәм үткәрү.

7. Гражданнар оборонасы хезмәтләре үз функцияләрен «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге буенча Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы идарәсе белән үзара бәйләнештә башкаралар.

## 3 бүлек. Гражданнар оборонасы хезмәтләрен булдыру тәртибе

8. Гражданнар оборонасы хезмәтләре булдырыла:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә - Башкарма комитет карары белән;

2) оешмаларда – җитәкче боерыгы яки приказы белән.

9. Гражданнар оборонасы хезмәтенең җитәкчесе булып, базасында хезмәт булдырыла торган оешма җитәкчесе (урынбасары) тора.

10. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең гражданнар оборонасы хезмәтләре, идарә органнары һәм милек формаларына һәм кайсы ведомствога каравына (буйсынуына) карамастан, төп эшчәнлекнең тиешле профильләре буенча берләшүче оешмалар базасында булдырыла.

11. Гражданнар оборонасы хезмәтен формалаштыру хезмәт составына керә торган һәм аны булдыру өчен иң яхшы шартлар булган оешмага (алга таба - гражданнар оборонасы хезмәтен формалаштыручы) йөкләнә.

12. Гражданнар оборонасы хезмәтен формалаштыручы хезмәт штабын төзи, кирәкле оештыру-план документларын эшли, хезмәт составына керә торган оешмаларның идарә органнарын, көчләрен һәм чараларын әзерләүгә методик җитәкчелекне гамәлгә ашыра.

13. Хезмәт штабы - тыныч вакытта һәм сугыш вакытында бурычларны үтәүгә әзерлеккә җитәкчелек итү һәм хезмәт көчләре һәм чаралары белән идарә итү өчен билгеләнгән хезмәт белән идарә итү органы.

14. Гражданнар оборонасы хезмәтләре штабы составына хезмәтләрне формалаштыра торган идарә органнарының вазыйфаи затлары, хезмәтләр составына кертелгән оешмалар (килешү буенча) җитәкчеләре һәм вазыйфаи затлары керә.

4 бүлек. Гражданнар оборонасы хезмәтләре белән җитәкчелек итү

15. Гражданнар оборонасы хезмәтләре белән гомуми җитәкчелекне тиешле гражданнар оборонасы җитәкчеләре гамәлгә ашыра.

16. Гражданнар оборонасы хезмәтләре белән турыдан-туры җитәкчелекне әлеге хезмәтләрнең җитәкчеләре гамәлгә ашыра.

17. Югары дәрәҗәдә гражданнар оборонасы әзерлегенең яки гадәттән тыш хәл режимы кертелгәннән соң, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе рәисе - Башкарма комитет җитәкчесе шәһәрнең тиешле гражданнар оборонасы хезмәтләре эшчәнлегенә оператив җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра.

18. Гражданнар оборонасы хезмәтләре эшчәнлеген координацияләүне Татарстан Республикасы ГТХМ «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге буенча идарәсе гамәлгә ашыра.

5 бүлек. Гражданнар оборонасы хезмәтләре белән идарә итүне оештыру

19. Гражданнар оборонасы хезмәтләре белән идарә итү хезмәтләрнең һәм аларның штабларының тиешле җитәкчеләре ягыннан, гражданнар оборонасы чаралары үтәлешен тәэмин итү буенча буйсынучы идарә органнары, авария-коткару формированиеләре, штатта булмаган формированиеләр белән тыныч вакыт һәм сугыш вакыты шартларында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү эшчәнлеген оештыруда, аларның әзерлеген тәэмин итүдә даими җитәкчелек итүне гамәлгә ашырудан гыйбарәт.

20. Гражданнар оборонасы хезмәтләре белән идарә итүнең нигезе булып хезмәт җитәкчеләренең һәм гражданнар оборонасының югарыдагы җитәкчеләренең карарлары, шулай ук тиешле хезмәтнең гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү планнары тора.

21. Гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итүне планлаштыру Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең һәм оешмаларның гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау планы (алга таба - гражданнар оборонасы планы) нигезендә гамәлгә ашырыла.

22. Гражданнар оборонасы планы хезмәт тарафыннан гражданнар оборонасы буенча махсус чаралар оештырылуын һәм үтәлү тәртибен билгели.

23. Гражданнар оборонасы планын эшләүне гражданнар оборонасы хезмәте җитәкчесе оештыра.

24. Гражданнар оборонасы планнарының структурасы һәм эчтәлеге буенча тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы тарафыннан эшләнә.

25. Гражданнар оборонасы хезмәтләренең планнары тиешле гражданнар оборонасы җитәкчеләре тарафыннан раслана һәм гамәлгә кертелә.

26. Гражданнар оборонасы хезмәтләренең бурычлары һәр конкрет хезмәт турында нигезләмәләр белән билгеләнә.

27. Гражданнар оборонасы хезмәтләре турында нигезләмәләр хезмәтләр җитәкчеләре тарафыннан эшләнә, хезмәтләр составына керә торган оешмаларның җитәкчеләре белән килештерелә һәм «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге буенча Татарстан Республикасы ГТХМ идарәсе тарафыннан раслана.

28. Гражданнар оборонасы хезмәтләре штабларының эшен оештыру, хәбәрләр бирү тәртибе һәм сроклары, гражданнар оборонасының башка хезмәтләре белән хезмәттәшлекне оештыру тиешле федераль башкарма хакимият органнары, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча идарә органнары тарафыннан билгеләнә.

29. Гражданнар оборонасы чараларын һәрьяклап тәэмин итү өчен гражданнар оборонасы хезмәте:

1) хезмәт эшчәнлеге профиленә туры килә торган авария-коткару формированиеләрен, гражданнар оборонасы чараларын үтәүне тәэмин итү буенча штатта булмаган формированиеләрне җәлеп итәләр;

2) гражданнар оборонасы бурычларын хәл итү өчен җәлеп ителә торган хезмәтләр, оешмалар составына керә торган формированиеләрне, аларның шәхси состав, техника һәм мөлкәт белән комплектлануын исәпкә алуны оештыралар.

6 бүлек. Гражданнар оборонасы хезмәтләрен комплектлау, матди-техник һәм финанс белән тәэмин итү тәртибе

30. Гражданнар оборонасы хезмәтләрен шәхси состав белән комплектлаштыру, техника һәм матди-техник чаралар белән җиһазландыру, базасында хезмәтләр булдырыла торган оешмалар хисабына, тиешле гражданнар оборонасы җитәкчеләре һәм гражданнар оборонасы хезмәтләре җитәкчеләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

31. Гражданнар оборонасы хезмәтләрен автомобиль транспорты, юл-төзелеш һәм күтәрү-транспорт техникасы белән тәэмин итү мобилизация үткәргәндә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә тапшырылырга тиеш булмаган ресурслар хисабына башкарыла.

32. Гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау чараларын финанслау Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2020 елның 14 сентябрендәге
4571 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең
гражданнар оборонасы хезмәтләре исемлеге һәм
составы

| № т/б | ГО хезмәтләренең исеме | ГО хезмәтләрен формалаштыручы | Фамилиясе, исеме һәм атасының исеме | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Хезмәт башлыгы | Хезмәт штабы башлыгы |
| 1. | Инженерлык | Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе | Ганиев Айрат Сәйдәш улы | Лотфрахманов Динар Илдар улы |
| 2. | Сәүдә һәм туклану | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсенең кулланучылар базары бүлеге | Солтанова Рәисә Кәүсәр кызы | Солтанова Алсу Хәйдәр кызы |
| 3. | Медицина | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсе | Николаев Александр Николаевич (килешү буенча) | Борһанова Айгөл Әбүзәр кызы (килешү буенча) |
| 4. | Коммуналь-техник | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | Альменеева Эльвира Емельяновна | Хәбибуллин Фидәрис Фәндәвис улы |
| 5. | Җәмәгать тәртибен саклау | Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе | Садыйков Данис Илһам улы (килешү буенча) | Солтанов Марат Фарасат улы (килешү буенча) |
| 6. | Янгынга каршы | ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең Дәүләт янгынга каршы хезмәте федераль янгынга каршы хезмәтенең 15 нче янгын сүндерү-коткару отряды | Юмагулов Рөстәм Наил улы (килешү буенча) | Хәйретдинов Марат Шамил улы (килешү буенча) |
| 7. | Элемтә һәм хәбәр итү | «Таттелеком» ААҖ филиалы - Яр Чаллы зона электр элемтәсе узелы | Ибраһимов Ринат Таһир улы (килешү буенча) | Устинов Андрей Юрьевич (килешү буенча) |
| 8. | Транспорт | Башкарма комитет шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенең транспорт һәм элемтә бүлеге | Парамонов Максим Геннадьевич | Фролов Вячеслав Юрьевич |
| 9. | Ягулык-майлау материаллары белән тәэмин итү | «Татнефть-АЗС Центр» ҖЧҖнең Чаллы филиалы | Хәбибрахманов Рәшит Гыйльфан улы (килешү буенча) | Вдовьев Сергей Владимирович (килешү буенча) |
| 10. | Юл | «Автомобиль юллары предприятиесе» муниципаль унитар предприятиесе | Анисимов Марат Александрович | Хөснетдинов Илнур Рафис улы |
| 11. | Энергетика | «Челтәрләр компаниясе» ААҖ филиалы - Яр Чаллы электр челтәрләре | Шаронов Эдуард Павлович (килешү буенча) | Штыков Дмитрий Алексеевич (килешү буенча) |
| 12. | Санитар- | «Татарстан Республикасында | Бариев Илгизәр | Ризванов Данияр |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | экологик күзәтчелек | гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең Яр Чаллы шәһәрендәге, Актаныш районындагы филиалы | Габделхалик улы (килешү буенча) | Әзһәт улы (килешү буенча) |
| 13. | Мәдәни кыйммәтләрне саклау | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | Галиева Алсу Рәҗәп кызы | Козлова Лилия Рамил кызы |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева